Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

26 март, 2026 ел № 38

Питрәч ав.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 217 номерлы карары белән (Советның 2020 елның 30 июлендәге 279 номерлы, 2021 елның 9 сентябрендәге 98 номерлы, 2022 елның 12 маендагы 159 номерлы, 2023 елның 18 маендагы 232 номерлы, 2023 елның 23 декабрендәге 273 номерлы, 07.12.2023 елның 294 номерлы, 2024 елның 6 мартындагы 304 номерлы, 2024 елның 5 декабрендәге 368 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5 статьяның 8 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов